**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«08» 07 2025 ел Яр Чаллы № 2255

Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия төзү турында

Тукай муниципаль районы заказчылары ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алганда, тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү максатында, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Федераль закон, сатып алуларны гамәлгә ашыру турында Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы заказчылары ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча түбәндәге составта комиссия төзергә:

комиссия рәисе – Галимова Гөлнара Әзһәт кызы, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;

комиссия рәисе урынбасары – Мадярова Дамира Әмирҗан кызы, Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече;

комиссия әгъзалары:

Бузина Нәзирә Камил кызы, Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы;

Шәйдуллина Резедя Сәүбан кызы, Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге башлыгы;

Храмова Виктория Николаевна, Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге әйдәп баручы белгече.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия составын кушымта нигезендә.

2.2. Комиссия Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 01 декабрендәге 3730 номерлы карары белән расланган сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә эшли.

3. «Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия төзү турында» муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2014 елның 08 январендагы 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип таныргa.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазифаларын башкаручы — Г.Ә. Галимова

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның «08» июлендәге 2255 номерлы карарына кушымта

Тукай муниципаль районы заказчылары ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия составы

Бердәм комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Галимова Гөлнара Әзһәт кызы | - Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары. |

Бердәм комиссия рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| Мадярова Дамира Әмирҗан кызы | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече. |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Бузина Нәзирә Камил кызы | - Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы; |
| Шәйдуллина Резедя Сәүбан кызы | - Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге башлыгы; |
| Храмова Виктория Николаевна | - Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге әйдәп баручы белгече. |